**Казан шәһәре Башкарма Комитетының**

2024 елның 6 июнендәге 2326 номерлы карары

# Казан шәһәре Совет районы Тополевая урамы буенча ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

1.1.1. йогынты ясала торган мәйдан – 72 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:250260:21, 16:50:000000:29967, кадастр кварталы өлеше 16:50:250260;

- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Совет районы, Тополевая урамы;

- билгеләү максаты: җирле әһәмияткә ия булган КТП-4042 комплектлы трансформатор подстанциясенең электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру;

- билгеләүвакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары (2018 елның 21 декабрендәге редакциядә), Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, җирле әһәмияттәге КТП-4042 комплектлы трансформатор подстанциясенә милек хокукы (2008 елның 14 апрелендәге 16-16-01/062/2008-503 номерлы) теркәлгән.

2. Әлеге карарның 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән һәм кадастр кварталы территориясенең бер өлешеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1 номерлы, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынтысы өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

4. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен һәм кадастр кварталы территориясенең бер өлешен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аннан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
6 июнендәге 2326 номерлы карары
белән расланды

**Казан шәһәре Совет районы Тополевая урамы буенча ачык сервитутның йогынтысы өлкәсе чикләре**




| | |
|---|---|
| Масштаб 1:100<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | яңа барлыкка килгән характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләренең чикләре |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:250260, 16:50:000000 | кадастр кварталы |
| 16:50:250260:21, 16:50:000000:29967 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |